**КАРАР**

**14 ноябрь, 2025 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары нигезендә 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары»

1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 226 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **123** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **123** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны:

«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срочлы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары»

1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Каримуллин